| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Нижневязовского городского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Зеленодол муниципаль<br>районы<br>Карамалы тау шэһэр<br>жирлеге башкарма<br>комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Карамалы Тау штп КАРАР

24.11.2017 №80

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, әлеге карарга кушымта нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга (алга таба – исемлек) бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мөлкәт бары тик аны биләүгә бирү һәм (яисә) озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына файдалануга бирү максатларында, шулай ук «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле нигездә түләүле нигездә читләштерелергә мөмкин дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль

районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында, шулай ук Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының административ бинасында урнашкан мәгълүмат стендында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкчесе А.М. Гыйниятов